

Олкәннәр айлыгы дәвам итә. Әле бу ай тәмамлангач та чәчләренә чал кергән буынны хөрмәт итv йозеннән матур чаралар vтәр.
Ромоданово районы Алтар топ гомуми белем бирv мәктәбенен 3нче, 5нче сыйныфларында бик матур чәй эчvгә укучыларынын кадерле әбиләре чакырылган. Сыйныф укучылары, яраткан әбиләрен соендереп, торле жырлар башкарганнар һәм кvнелгә vтеп керерлек иттереп шигырьләр укыганнар. Бу кон һәркем очен чын бәйрәмгә әверелгән.       Авыл администрациясе коче белән дә әзерләнгән чара олкән буын вәкилләрен матур жырлар белән ләззәтләнергә, кvнелле ял итәргә момкинлек биргән. Бәйрәм кунакларын котлау сvзләре белән Алтар авыл жирлеге башлыгы Монир Хафиз улы Кузяев һәм башкалар чыгышларында олы яшьтәге кешеләргә башкарган эшләре очен рәхмәт белдерделәр, ә кvбесе әле дә жәмгыятькә, гражданнарга хезмәт итvен дәвам итә. Алар хормәтле кунакларга иминлек, нык сәламәтлек, бетмәс-токәнмәс энтузиазм, яхшы кәеф, бары тик унай хис-кичерешләр һәм озын гомер теләделәр.
Зирәклеккә һәм тәжрибәгә хормәт белән бәйрәм концертын Алтар мәдәният йорты vзешчәннәре катнашында чын бvләк булган.
Тагы бер жылы очрашу vткән. Дубенка районы Ломат авылынын туган якны ойрәнv музеенда олкәннәр коненә багышланган “Йорәк жылысы - кайгырту һәм хормәт” дигән чара узган.
Зирәклеккә һәм тәжрибәгә хормәт бәйрәме тантанасын Ломат музеенда, таныш экспонатлары арасында уздырганнар. Биредә бәлешләр һәм тәм-томнар белән әзерләнгән остәлгә авылнын якын һәм кадерле кешеләре булган ата-аналары, әби-бабалары очен ин ягымлы, ин назлы сvзләргә, рәхмәтләргә лаек олкән буынны сәламләп каршы алдылар. Алып баручы музей житәкчесе Мәзидә Якуб кызы Муракаева кунакларны бәйрәм белән котлап нык сәламәтлек, гаилә иминлеге, муллык һәм озын гомер теләгән. Сәламләv сvзе белән ветераннар Советы рәисе якташларынын хормәтен яулаган Венера Сәләх кызы Алеева чыгыш ясаган, кунакларга авылнын хормәтле Альмира Бари кызы Раимова да бик кvп жылы сvзләр әйткән. Шулай ук авылдашларын олы стажлы педагог Тәнзилә Айса кызы Пикеева котлаган.
Рәсми олештән сон конкурсларга һәм викториналарга кvчкәннәр. Чәй янында бәйрәм кунаклары бер-берсен котлап исәнлек-саулык теләп кенә калмаганнар, vткән елларны искә алып, чын кvнелдән жырлаганнар, әнгәмә корганнар. Гаиләдәгечә якты кvнел, жылы могалләмә, юмор белән аралашып вакыт vтеп киткәнен сизмичә дә калганнар: олы буын вәкилләре ойләренә тик яхшы кәеф белән таралышканнар.

**Н.ХӘЛИЛ**